РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» апрель, 2016 ел Олы Кайбыч ав. № 33

Кайбыч муниципаль районы башлыгына, Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасарына, Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә, кайбыч муниципаль районы Советы депутатларының вазыйфаларын биләүче затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм счетларга (кертемнәргә) ия булырга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яисә) алардан файдаланырга тыю турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7.1 ст., «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда каралган очракларда чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) файдалану тыела, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела:

1) түбәндәге вазыйфаларны биләүче затларга:

- Кайбыч муниципаль районы башлыгы;
- Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасары;
- Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе;
- Кайбыч муниципаль районы Советы депутатлары.

2) әлеге карарның 1пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән затларның тормыш иптәшләренә һәм балигъ булмаган балаларына.

2. Әлеге статьяда билгеләнгән тыюны үтәмәү вәкаләтләрне вакытыннан алда туктатуга, биләгән вазыйфасыннан азат итүгә яисә тиешле затның хокукый статусын билгеләүче федераль конституциячел законнар һәм федераль законнар нигезендә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итүгә китерә.

3.Әлеге карарны «Кайбыч таннары» район газетасында бастырып чыгарырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

**Совет Рәисе-**
**Кайбыч муниципаль районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**